КЫЙММӘТЛЕ ЧАКРЫМНАР

Илкүләм проект кысасында башкалада 33,8 чакрым юл төзекләндерелде

> 2

ФӘҮЗИЯ СӘЙФЕТДИНОВА:

«Рәссам Харис Якуповка, эшне бүлдереп йөрмәгез әле, дия идек»

> 4

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Мәхәббәттә склероз – бәлки, иң кирәкле нәрсәләрнең берседер»

> 4

БАЛА ХӘСРӘТЕ

Бәхетсезлегемне эзләп, Сарсаз авылына кияүгә чыктым...

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 181 (28954) | Чәршәмбе | 7 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Уртага салып сөйләшү

«Кеше башын бутамагыз!» Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов эшмәкәрләр белән очрашуда җитәкчеләргә әнә шулай дип белдерде. Ул үз тамагын үзе туендырып яшәүчеләрдән йөз чөермичә, киресенчә, аларга ярдәм итү җаен эзләргә кушты. Кайвакыт моның өчен бер сүз дә җитә. Бигрәк тә Президент әйтсә!

tatarstan.ru

ЭШ ҺӘМ АШ

ПРЕЗИДЕНТ ЭШМӘКӘРЛӘРНЕҢ ХӘЛЕН БЕЛЕШТЕ

«Вазгыять үзгәрде. Бүгенге шартларда кече һәм урта бизнеска эшләргә шартлар тудыру мөһим. Моның өчен федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге программалар җитәрлек. Мин дә сезне тыңларга әзер», – диде Рөстәм Миңнеханов Биектау районында узган чарада. Ә эш кешесенең кыенлыклары җитәрлек. Быелның 11 аенда Татарстан Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә 3 меңнән артык зар хаты килгән. «Аларның 70 процентын тиз арада хәл итә алдык», – диде вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев. Борчулы эшмәкәрләрне очрашуга да чакырганнар.

Заманасына күрә – чире, дигәндәй, «Полладиум» аудиторлык оешмасы вәкиле Алсу Гобәйдуллина республика җитәкчесенә көн кадагында торган мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте.

– Бүген эшмәкәрләр дә, оешмалар да мобилизацияләнгән солдатларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүдә шактый зур эш башкара. Медицина кирәк-яраклары белән дә, кием-салым белән дә булышырга тырышабыз. Тик шунысы бар: бушлай ярдәм итүгә киткән чыгымнарга салым түләргә кирәк. Бу – гадел түгел, – диде Алсу Гобәйдуллина.

Президент хәрби хезмәткә китүчеләргә ярдәм итүдә катнашкан һәркемгә рәхмәт сүзләрен җиткерде. «Моңа бәйле мәсьәләләрнең күбесен бюджет кысасында хәл итәргә тырышабыз. Әмма оешмалар, эшмәкәрләр ярдәменнән башка булмый», – диде ул. Хәйрия белән шөгыльләнүчеләрне салымнан азат итүнең бездән генә тормаганын аңлап, сорауны Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәрраховка юллады. Мәсьәлә урында ук хәл ителде. Баксаң, әлеге эчтәлектәге канун әле күптән түгел, ноябрь азагында кабул ителгән икән инде. «Хәзер бушлай ярдәмгә салым юк. Канун кире көчкә ия һәм ул быелның 1 гыйнварыннан эшли», – диде Айрат Фәррахов.

Киләсе җәйгә республика паркларын һәм скверларын да үзгәрешләр көтә. Биредә ял итү өчен мөмкинлекләрне тагын да арттырачаклар. Рөстәм Миңнеханов кирәкле документларга үзгәрешләр кертү өчен ике ай вакыт бирде. Түбән Камада эшмәкәрләр хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Илнар Сираев ял мәйданнарында үз эшеңне оештырып булмаудан зарланды. «Башкаладан аермалы буларак, республика парклары һәм скверларында сәүдә генә рөхсәт ителгән, башка хезмәтләр гомумән юк. Югыйсә, җәен – шул ук сәпид, кышын чаңгы-чананы арендага биреп булыр иде. Паркта тәм-том ашап йөрергә генә димәгән. Чәчтарашлар да, мәсәлән, җәй көне рәхәтләнеп паркларга чыгып эшләргә риза. Тик бу ярамый», – диде Илнар Сираев. Мәсьәләгә Татарстан шәһәрләрен үстерү институты директоры Наилә Җиһаншина ачыклык кертергә тырышты. Аның әйтүенчә, гамәлдәге канун нигезендә парклар һәм скверларда сәүдә рөхсәт ителә, ә башка төр хезмәтләр – юк. «Ярамыймы, әллә мондый хезмәтләр күрсәтү законга кертелмәгәнме?» – дип сүзгә кушылды Президент. «Законда бу юк», – дигән җавап ишеткәч, җитәкчегә кеше башын бутамаска киңәш итте. «Тыелган белән законда күрсәтелмәгәнне бутамагыз. Бу – икесе ике нәрсә. Прокурор бирәдә. Бергәләп киңәшергә дә гамәлдәге законга үзгәрешләр тәкъдим итәргә кирәк. Моның өчен күпме вакыт кирәк? Ике ай вакыт бирәм, 15 февральгә кадәр әлеге мәсьәләне хәл итегез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әлмәт эшмәкәре Әлфия Гобәйдуллинаның – үз борчуы. Баксаң, киоск, павильон ише кечкенә сәүдә нокталары чүп чыгарган өчен зур кибетләргә караганда да күбрәк түли икән. «Минем кечкенә кибетем бар. Без стационар булмаган сәүдә ноктасы булып саналабыз. Каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен бик зур суммада акча исәплиләр. Көндәшлек өчен тигез шартлар булырга тиештер бит. Тарифларга бәйле документларда хата китмәдеме икән?» – дип зарын җиткерде ул. Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, тариф – күктән алган сан түгел. «Без ел дәвамында төрле сәүдә объектларында күпме көнкүреш калдыгы чыкканын тикшердек. Язын – язга, җәен – җәйгә чүп чиләкләрен бушатып, үлчәп бардык», – диде министр. Рөстәм Миңнеханов исә, гаеп атта да, тәртәдә дә, дигән фикердә. «Әлеге мәсьәлә миңа кадәр барып җиткән икән, димәк, тагын бер кат карап тикшерергә кирәк. Барысы да гадел булырга тиеш. Эшмәкәрләрнең шиге бар икән, яңадан үлчәгез. Тарифларны күрше төбәкләр белән чагыштырып карарга да кирәк», – диде ул.

Ахыры 3 нче биттә >

Яңа ярдәм чарасы

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен яңа ярдәм чарасы кертелә. Хәзер аларның яңа туган балалары өчен сабый кирәк-ярагыннан торган бүләк җыелмалары тапшырылачак.

Моңа кадәр мондый бүләк аз керемле гаиләләргә генә бирелә иде. Хәзер ул хәрби операциядә катнашучыларның һәммәсе – мобилизацияләнүчеләр, «Алга» һәм «Тимер» батальоннары, Росгвардия хәрби хезмәткәрләре, шулай ук һәлак булганнарның гаиләләренә дә тапшырылачак. Ярдәм җыелмасын алу өчен, яшь ана иренең махсус хәрби хезмәткә чакырылуын раслаучы документларны тапшырырга тиеш.

Дуңгыз гриппы килә

Татарстан – халыкны гripptан вакцинацияләү буенча 78 нче урында. Роспотребнадзор сайтында урнаштырылган рейтингтан әнә шуны күрергә мөмкин. Анда, илнең яңа төбәкләрен исәпкә алмыйча, 85 субъектта вакцинация уздыруга кагылышлы мәгълүматлар китерелгән.

Татарстанда яшәүчеләрнең 44,7 проценты (балаларны да кертеп) прививка ясаткан. Вакцинация буенча иң яхшы күрсәткечләргә – Тыва (61,5%), Чечня Республикасы (60,5%), Ханты-Манси автономияле округы (60,4%), Төмән өлкәсе (6,1%) ирешкән.

Әле шушы көннәрдә генә Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе матбугат хезмәте республикада 1,3 миллионнан артык кешенең грипптан прививка ясатканын хәбәр иткән иде. Бу – планның 56,4 проценты (халыкның 36,7 проценты). Быел Татарстанда барлыгы 2417328 кеше прививка ясатырга тиеш.

Сүз уңаеннан, республикада грипп йоктыруның 67 очрагы ачыкланган. 59 кеше дуңгыз гриппын (AH1N1 штаммы) йоктырган. Грипп ияртү очракларының 88 проценты әлеге хәтәр штаммга туры килә.

Күпбалалыларга – җир кишәрлеге

Районнарда, Казан һәм Чаллыда яшәүче күпбалалы гаиләләргә барлыгы 44492 җир кишәрлеге бирелгән. Кишәрлекләр 3 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә тәгаенләнгән.

Исемлекләргә тагын 71297 гаиләне кертү турында карар кабул ителгән. Шул исәптән Казанда – 18097, Чаллыда – 9248 күпбалалы гаиләне.

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгечләре әйтүенчә, республикада барлыгы 48379 җир кишәрлеге кадастр учетына куелган.

Койрыкка басалар

Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре ел башыннан бирле Татарстанда хәмернең законсыз әйләнеше буенча 81 җинаять һәм 315 хокук бозу очрагын ачыклаган.

Шулай итеп, быел 10 ай эчендә республикада барлыгы 214563 литр күләмендә хәмер әйләнештән алынган. Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары Александр Чубаров әйтүенчә, узган елда республикада 270275 литр спиртлы эчемлек сатудан алынган, 112 җинаять һәм 1075 хокук бозу очрагы билгеләнгән булган. Аның фикеренчә, хәмерне законсыз җитештерү-сатуга каршы көрәш эчкечелекне киметүдә төп эш юнәлешләренең берсе булып тора.

Ишеттегезме?

Имзаланды

Россия Президенты Владимир Путин күп кенә федераль законнарга кул куйды. Шуларның иң әһәмиятлеләрен барладык.

ЛГБТны пропагандалауны тулысынча тыю турында. Гадәти булмаган җенси мөнәсәбәтләрне, җенесне алыштыруны һәм педофилияне рекламалауны тыю каралган закон үз көченә керде. Хәзер социаль челтәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чаралары, кинода аларны тарату тулысынча тыела. Моңа кадәр балигъ булмаган үсмерләргә карата гына ЛГБТ, педофилияне пропагандалау рөхсәт ителмәсә, хәзер бу барлык кешегә кагыла. Законны бозган өчен 10 миллион сумга кадәр штраф күздә тотылган.

Митингларны тыю турында. Яңа законда митинглар үткәрү тыелган урыннар исемлеге киңәйтелгән. Моннан ары хакимият органнары биналарында һәм аларның тирә-юнендә, аэропорт, тимер юл һәм автомобиль вокзаллары, порт, вуз, мәктәп, хастаханә биналары һәм аларның тирә-юнендә, дин йортлары территорияләрендә митингка чыгарга ярамый.

Тикшерү комитетының штатын арттыру турында. Владимир Путин комитет хезмәткәрләре санын мең кешегә диярлек арттыру турында указга кул куйган. Хәзер хезмәткәрләрнең штаттагы саны 21989 кешегә җитәчәк. Штат саны 863 тикшерүче вазыйфасына ишәя. Бу илнең яңа субъектларында Тикшерү комитетлары булдырылуга бәйле.

2023 елда яшәү минимумы турында. Яңа законда Россиядә җан башына яшәү минимумы күләме – 14375 сум, эшләүчеләр өчен – 15669 сум, пенсионерлар өчен – 12363 сум, балалар өчен 13944 сум күләмендә билгеләнгән. Исегезгә төшерәбез: быел федераль МРОТ күләме 13890 сум тәшкил итә.

Ана капиталыннан айлык пособие түләү турында. Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә ана капиталыннан айлык пособие түләү турында закон имзаланды. Аның күләме – төбәктә балалар өчен билгеләнгән бер яшәү минимумы. Тик яңа пособие җан башына туры килә торган керемнәре ике яшәү минимумыннан артмаган гаиләләргә генә билгеләнергә мөмкин.

2025 елга кадәр пенсиянең тупланма өлешен «катыру» турында. Асылда закон аны 2014–2024 елларга «катыру»ны тагын бер елга озайта. Хезмәт хакының 6 проценты иминият өлешенә, ягъни бүгенге пенсионерларга түләүгә җибәрелә, дигән сүз бу. Сүз уңаеннан, 2014 елга кадәр акчасын тупланма булдыруга җибәрергәме яки иминият өлешенәме (бу очракта пенсия күләмен исәпләү өчен баллар арта) икәнен һәрбер кеше үзе хәл итте.

Мобилизацияләнүчеләрнең дәүләт хезмәтендә булуын туктатып тору турында. Дәүләт хезмәткәре эшкә чыккан көнне дәүләт хезмәте яңартыла.

Даруханәләрдә дарулар ясау турында. Россия Президенты даруханәләрдә дару препаратлары җитештерүне яңартып җибәрүне күздә тоткан законга кул куйды. Шулай итеп, аптекалар табиб рецепты буенча дару ясау хокукы ала. Ләкин бу шәхси эшмәкәрләр ачкан даруханәләргә кагылмый.

Инвалид балаларның әти-әниләре өчен 24 өстәмә ял көне турында. Закон инвалид бала тәрбияләүчеләргә бер ел эчендә бер тапкыр рәттән егерме дүрт көнгә кадәр түләүле өстәмә ял бирүне күздә тота. Мондый ял дүрт көннән арткан очракта, аны эш бирүче белән килештерергә кирәк булачак.

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президентының матбугат сәркатибе:

Социаль челтәрләрдә мобилизациянең яңа дулкыны турында бик күп коткылы хәбәрләр таратыла. Президенттан һәм Оборона министрлыгыннан килгән мәгълүматка гына ышанырга кирәк. Мобилизациягә килгәндә, Президент бу уңайдан үз сүзен әйтте инде. Шуңа күрә юк-бар хәбәрләргә игътибар итмәскә кирәк.

(Журналистлар белән очрашуда әйткән сүзләре)

РОССИЯДӘ – ЗЫЯНЛЫ ГАДӘТЛӘР

«РИА-Рейтинг» агентлыгы ил төбәкләрендә яшәүчеләрнең зыянлы гадәтләргә карашын белешкән. Узган ел белән чагыштырганда, Россиянең 66 төбәгендә хәмер эчүчеләр, тәмәке тартучылар арткан, 18ендә кимегән.

1 >> Чечен Республикасы
2 >> Дагыстан
3 >> Ингушетия
...
11 >> Тамбов өлкәсе
...

22 >> Чувашия
...
31 >> Татарстан
...
84 >> Камчатка
85 >> Хакасия Республикасы

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен; гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен; гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

МОНГОЛИЯ ХАЛКЫНА НИ ҖИТМИ?

Яңа атна гыйсъянчылыкның яңа күтәрелеше белән башланды. Бу юлы тын гына яшәп яткан монгол башкаласы фетнә үзәгенә әверелде. Кытайда монгол ташкүмерен урлауда катнашкан чиновниклар үлем җәзасына тартылды, чиннар Монголиянең Премьер-министры Лувсаннамсрайну Оюун-Эрдэнэга бу эшкә катнашы булган монгол түрәләренең исемлеген ачты дигән хәбәр протестка этәргеч бирде. Берничә көн элек үк шул уңайдан монгол яшьләре мәйданга чыгып тузгый башлаган икән инде. Әмма ул хакта иң эре монгол мәгълүмат агентлыклары берни дә хәбәр итмәгәннәр. Яңалык Россия мәгълүмат кырына чыккач та, әле илнең төп мәгълүмат агентлыгы Монцамә берни дә эндәшми, диләр. Монголия Конституциясе буенча, дәүләт массакүләм мәгълүмат чаралары тота алмый. Дәүләтнеке булмаган агентлыклар да, күрәсең, уңайсыз хәбәрләрне мәйданга чыгарудан сакланалар. Димәк, чиновниклар кулында аларга тәэсир итү чаралары бар.

Россиянең мәгълүмат кырына фетнә турындагы беренче хәбәр, баш күтәрүчеләр Хөкүмәт йортын яуларга тырышалар, дигән сүзләр белән килеп керде. Ярсыган халык 44 триллион тугрикның (12,9 миллиард доллар) ташкүмер урлаган коррупционерларны ачыклау таләбе куйды. Премьер-министрның каракларны тикшерү өчен эшче төркем төзүе, аның составына баш күтәрүчеләрне дә чакыруы хакында хәбәр күренгәч тә, протест тынмады, гыйсъянчыларның агрессивлыгы арта гына, диделәр. Идарә итүче Монгол халык партиясе лидеры Дашзэгвийн Амарбаясгаланның күмер караклары арасында хөкүмәтнең һәм ведомстволарның 15 вәкиле барлыгын әйтүе дә эшкә нокта куймады. Душәмбе киченә башкала губернаторының демонстрациям көч кулланып куып тарату турында фәрманы да билгеле булды.

Караклык масштабы кайбер аналитикларда шик уятты. 12,9 миллиард долларлык ташкүмер урлау өчен, бөдкетка бер түгрик та түләмичә, ел ярым буена барлык экспорт керемен үз кесәнә салып барырга кирәк, дип күренә. Әмма Кытайда каракларны җәзалап үтерүләрен, андый процессларның озак баруын исәпкә алсак, сүзнең бик күп еллар дәвамында урланган акчалар турында барулын аңларлык.

Фетнә уңаеннан «Кем кулы уйнады?» дигән сорау туа бит һәрчакта да. Берсе – Кремль аркадашы, икенчесе АКШның дәүләт департаменты тарафдары булган элекке ике президентка шик төшә икән. Илдагы президентлар фетнә турында күпме беләдер, әмма андый стихияле күтәрелешләрне аерым кешеләр оештыра алмый. Идарәче түрәләрнең аяусыз талавыннан интеккән халык массалары урамга ничек җыелганнарын үзләре дә аңламый кала. Гамәлдәге җитәкчелек исә җавапланылыны үз өстенә алырга курка. Кемнәргәдер төртеп күрсәтеп котылмакчы була. Башланган фетнә дилбегәсен, чынлап та, элекке җитәкчеләр кушуы буенча кемнәрдер үз кулына алырга тырышырга мөмкин, әлбәттә. Фетнә җиңгән очракта яңа лидерлар я Мәскәү, я Пекин, я Вашингтон кубызына биергә тотына да алалар. Чит дәүләтләр үзләре яклы лидерларны финансларга да мөмкин, әмма фетнә өчен алшартны һәрвакытта да гамәлдәге идарәчеләр үз сәясәтләре белән тудыра. Монгол фетнәсенең кая кадәр барып җитәсен әйтеп булмый. Мөгаен, ул бастырылыр, әмма ризасызлык өчен җирлек барыбер калыр.

Россиядә

ДОЛЛАРДАН КАЧУ

Россия Үзәк банкы доллар һәм евродан тулысынча баш тарту турында ныклы карарга килде. Регуляторның отчетында алдагы өч елда резерв валюталары булып саналган Көнбатыш кәгазьләреннән мөмкин булган дәрәҗәдә арыну турында мәгълүмат бар. «Девалютизация» дип аталган шаукымны башлап җибәрү экспорт компанияләренә йөкләнә. Алар үз товарлары башка илләрнең акчаларына сатарга тиеш булалар. Шуннан соң илгә доллар һәм евро агымы туктала. Дәүләт компанияләре дә саклык акчасын «агулы» валюталарда түгел, башка юл белән саклауга күчәргә тиешләр. Россия компаниясе сумнарда саклерга тиештер инде табышын. Бу карарга китергән сәбәпләр бик аңлаешлы. Банк хисабына кергән электрон валюталарга чит илләрдән товар сатып алу бик кыен. Бигрәк тә стратегик яктан әһәмиятле товарларга юл бикле. Аннан соң Америка банклары, акча Россия банкы хисабында торса да, бик җиңел генә аны тыңдырып куя алалар. Андый хәвефле шартларда «канфит кәгазе»нә әйләнеп барган валюталардан теләсән-теләмәсәң дә качарга туры килә. Россиягә бит хәтта кәгазь доллар һәм евро да бирмиләр. Капчыклап акча ташып та товар кайтарта алмыйсың.

Вазгыятьнең кыен һәм хәтта куркыныч та ягы шунда: тышкы сәүдә өчен кайсы валютаны сайларга? Кытай юане тотрыклы түгел, үз икътисадлары кебек чайкалып тора. Аннан соң икътисадыңны Кытай акчасына кучердерне, ул державага бәйле буласың. Кытайлар болай да юаньне файдалану мөмкинлекләрен чиклиләр, кыенлыклар тудыралар. Сәүдәне ниезнадә Азия юлбарысы булып саналган гигант белән генә алып барырга туры киләчәк. Безнең чималны арзанга таләп итәчәкләр, үз товарларын гына сатып алуны сораячаклар. Кытай өчен файдалы, безнең өчен авыр шартлар туачак.

Хәзерге глобаль кризис, икътисадлар чәкешү, һәр илнең юрганны үз өстенә тартуы шартларында ышанычлы валюта булмау – бик зур проблема ул. Әйе, экспортны сумнарга көйләргә тырышып карарга була. Әмма Россиягә андый бонус бирергә атлыгып торган илләр бик күп күренми әле. Газны Көнбатышка сумнарга сатып карадык бит инде. Базарны югалттык диярлек, бары шул гына.

Бу катлаулы вазгыятьтән чыгу юлы бар ул үзе барын. Алтын акчага күчәргә мөмкин. Теоретик яктан карагандa, иң дөрес юл шул. Үз чималыңны алтынга сатасың, алтын тәңкәләр коясың, шулар күләмендә алтын стандартка буйсынган кәгазь акча да басып була. Соңгысы ышанычлы түгел, чөнки кәгазьне алтынга караганда күбрәк басып алдарга мөмкиннәр. Әмма алтын акчага бөтен дөньяның финанс системасы каршы. Ул гамәлгә керсә, ислам шаригате кысасында гына эш йөртеп була: процентлар бетә, фонд базары юк итеглә. Спекуляция ярдәмендә җиңел генә баеп китә алмыйсың. Агымдагы вазгыятьтә моның белән бер олигарх та килешмәячәк. Ә хакимлек әлегә шулар кулында.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

«Эверест», «Максат» һәм «Минзәлә». Татарстанда берьюлы өч футбол манежы ачылды. Биектауда урнашкан «Эверест»та Президент Рөстәм Миңнеханов тупка үзе типсә, Буа һәм Минзәләдә ачылыш тантанасы видеоконференция элемтәсе аша узды.

«Футболны барыбыз да ярата, әмма бездә аны җәй көне генә уйнап була. Татарстандагы программа буенча һәр районда ябык футбол манежы барлыкка киләчәк. Быел без өсте ябылган 6 манеж төзедек, аңа кадәр дә шуның кадәр ачкан идек. Киләсе елда тагын 4 дүрт корылма төзү планлаштырыла. Шулай итеп, республика районнарында яшәүче барлык балаларның да футбол уйнау мөмкинлеге булачак», – диде Президент ачылыш тантанасында һәм спорт җиһазлары алу өчен сертификат тапшырды.

Футбол манежлары республикада спорт корылмаларын төзү программасы кысасында төзелә. Спорт комплекслары 2020 елда – Яшел Үзәндә, былтыр – Әлмәт, Бөгелмә, Зәй, Чистай һәм Әгерҗедә (инвесторлар хисабына), быел исә Буа, Биектау, Минзәлә, Алабуга, Мамадыш һәм Нурлатта ачылды. 2023 елда футбол манежлары Азнакай, Питрәч, Актаныш һәм Апас районнарында төзелер дип көтелә.

«АДЫМНАР»НЫҢ ЗУР ҖИҢҮЕ

Татарстанның күп телдә белем бирүче «Адымнар» мәктәбе ЮНЕСКОның ассоциацияләнгән мәктәбе статусына (әлеге оешма белән хезмәттәшлек итүне аңлата) һәм тиешле сертификатка ия булган. Бу хакта Россиянең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе секретаре Георгий Орджоникидзе Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының яшьләр моделен үткәрү кысасында хәбәр итте.

– Бездә – зур яңалык. ЮНЕСКО секретариатының дустанә булмаган мөнәсәбәте шартларында да сертификат һәм ассоциацияләнгән мәктәп статусы алуга ирештек. «Адымнар» мәктәбенә шундый статус бирү турында карар әле кичә генә кабул ителде. Хәзер безнең челтәрдә тагын бер оешма – иң лаеклы оешма бар, – диде ул.

ЮНЕСКОның ассоциацияләнгән мәктәпләре челтәренә керүче уку йортлары ЮНЕСКО кыйммәтләрен алга сөрә. Мондый мәктәпләр яшьләрне толерантлык рухында укытутәрбияләү бурычын куя.

Орджоникидзе сүзләренә караганда, ассоциацияләнгән мәктәпләр башлангыч һәм урта белем бирүне үз өченә ала. Мондый халыкара челтәрдә укучылар һәм укытучыларның халыкара хезмәттәшлеген булдыру мөмкинлеге бирә. Алар ЮНЕСКО билгеләгән темалар буенча башка илләр мәктәпләре белән хезмәттәшлек итә, тикшеренүләр үткәрә. Хәзер урта техник белем бирү буенча да шундый ук халыкара челтәр булдыру күздә тотыла.

Казанның «Адымнар» мәктәбе директоры Айдар Шәмсетдинов фикеренчә, ЮНЕСКОның ассоциацияләнгән мәктәбе статусын алу – гаять зур җиңү ул. «Белүемчә, соңгы ике елда анда беркем дә рәсми төстә кабул ителмәде», – дип билгеләп үтте директор.

Исегезгә төшерәбез: Татарстанда инде алты «Адымнар» мәктәбе эшли. Укучылар аларда өч телдә – рус, татар һәм инглиз телләрендә белем ала. Республикада күп телдә белем бирүче мәктәпләр челтәрен булдыру проекты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, 2019 елдан бирле тормышка ашырылып килә.

ЮНЕСКОның ассоциацияләнгән мәктәпләр челтәре исә 1953 елда оештырылган. Россия (ул чагында – Советлар Союзы) бу хәрәкәткә 1966 елда кушылган.

«Татар-информ»

Кыйммәтле чакрымнар

Быел Татарстанда юл эшләренә 193 миллиард сум акча сарыф ителгән. Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин сүзләренә караганда, агымдагы елда республикада 443 чакрым озынлыкта төбәк һәм 630 чакрым җирле әһәмияттәге юллар төзекләндерелгән.

Моннан тыш авылларга илтүче 120 чакрым юл яңартылган. Бу эш республикада гамәлдә булган өч социаль программа кысаларында башкарылган.

– «Сыйфатлы куркынычсыз юллар» илкүләм проекты кысасында быел башкалада 33,8 чакрым озынлыктагы алты урам юлы төзекләндерелде. Моңа 2 миллиард сум акча сарыф ителде, – ди министр урынбасары.

Киләсе елда әлеге проект кысасында юл эшләрен башкаруга 11,2 миллиард сум акча бүлеп бирелгән. Шуларның 4,7 миллиард сумы – федераль казнадан, 6,5 миллиард сумы республика бюджетыннан бүленгән. Әлеге акчаның 5,8 миллиард сумын – шәһәр агломерацияләренең транспорт тармагын үстерүгә, тагын 1,4 миллиард сумын эре инфраструктур проектларны тормышка ашыруга сарыф итмәкчеләр. Әлеге проект нигезендә киләсе елда 26 күперне дә төзекләндерергә җыеналар.

Чукин сүзләренә караганда, «Сыйфатлы куркынычсыз юллар» илкүләм проекты буенча киләсе ел азагына кадәр җирле әһәмияттәге юллар саны 51,6 процентка артырга тиеш. Тиешле нормативларга җавап биргән шәһәр юлларын күрсәткеченә дә 85 процентка кадәр җиткермәкчеләр.

Артем Чукин Вознесение тракты язмышына да ачыклык кертте. Аны 2024 елда төзеп бетерергә планлаштыралар. «Тиешле финанс чыганаклары булса, без аны контрактта күрсәтелгән вакытта әлгертергә тырышачакбыз», – ди министр урынбасары.

Билгеле булганча, Вознесение тракты 2021 елның җәендә төзелә башлады. Быел март аенда аның икенче этабына керештеләр. Казанда Гвардия урамыннан алып Җиңү проспектына кадәр 4 чакрым һәм Җиңү проспектыннан М7 трассасына кадәр 8 чакрым озынлыкта юл салынды.

Татарстан җылы җибәрә

Төзелеш материаллары, җылы кием, азык-төлек кебек кирәк-ярак төялгән җиде йөк машинасы... Татарстан Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәренә гуманитар ярдәм юллады.

«Ярдәм яңашә!» хәрәкәте координаторы Тимур Сафин сүзләренә караганда, 140 тонналык әлеге гуманитар ярдәмне җыюда республика халкы, вуз һәм оешмалар, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге катнашкан. Бу савапны гамәлгә районнар да зур өлеш кертә. Гуманитар ярдәм төялгән йөк машиналары арасында Баулыдан килгәннәре дә бар. Бу юлы республикада Лисичанск халкына күбрәк җылы киемнәр, электрогенератор һәм җылытыкч җайланмалар җибәрергә тырышканнар. Ник дигәндә, бүген шәһәр җылыга мохтаҗ.

«Ярдәм яңашә!» хәрәкәте активистлары бүген чираттагы гуманитар ярдәмне әзерләү белән мәшгуль. Аны киләсе атнада ук җибәрергә җыеналар. Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләргә гуманитар ярдәм әзерләүдә теләге булган һәркем катнаша ала. Тулырак мәгълүматны «ярдәм.рф» сайтында яки 8-800-350-02-16 номеры буенча «кайнар элемтә»гә шалтыратып белергә мөмкин.

Россия Оборона министрлыгы махсус хәрби операция зонасында кыр почтасы эшен оештырган. Хат ташу белән кораллы көчләрнең фельдъегер-почта элемтәсе бүлекчәләре шөгыльләнә. Хәзерге вакытта хәрби хезмәттәге яр-егеткә хат язып җибәрү өчен, аның хәрби часте номерын белергә кирәк. Мобилизацияләнүчеләргә хәрби часть номеры алар хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр ителгән. Шуннан бирле номер үзгәрмәгән. Ниндидер сәбәп белән хәрби часть номерын белмәгән очракта, солдатларның якыннары район-шәһәр хәрби комиссариатына мөрәҗәгать итә ала. Аларның телефоннары Татарстан Хәрби комиссариатының рәсми сайтына урнаштырылган. Хатларны, шулай ук посылкаларны «Почта России» бүлеге аша түбәндәге адрес буенча юлларга була: «103400, город Москва-400, хәрби часть номеры». Алар гади хат кебек китә. Хәрбиләр үзләре дә хат язып җибәрә ала. Моның өчен аларның һәркайсы почта конвертлары һәм язу кирәк-ярагы белән тәэмин ителәчәк.

ЭЛЕМТӘЛӘРНЕ НЫГЫТЫП

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә эшлекле сәфәрдә. Анда ул Россия Закон чыгаручылар советы чараларында катнаша. Республика парламенты башлыгы кичә Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе (аңа үзе җитәкчелек итә) утырышын уздырды. Парламентчылар, агымдагы елдагы эшкә йомгак ясап, яңа геосәяси шартларда Россия төбәкләренең халыкара элемтәләрен үстерү мәсьәләләрен карады.

«Закон чыгаручылар советы, Президиумы һәм комиссияләре, гадәттәгечә, декабрь аенда үзләренең эшенә йомгак ясап, киләсе елда хәл ителергә тиешле бурычларны билгели, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе утырышына йомгак ясап. – Бүген без икътисади һәм мәдәни элемтәләр географиясен яңабаштан карыйбыз, дустанә илләр белән хезмәттәшлекне көчәйтәбез».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Азия – Тын океан регионы илләре һәм ислам дәүләтләре хезмәттәшлекнең перспективалы юнәлешләре булып тора. Бу җәһәттән Татарстанның әйбәт кенә уңышлары бар, Ислам хезмәттәшлеге оешмасына керүче илләр белән күпьяклы элемтәләр җайга салынган. «Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Владимир Путин кушуы буенча «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменә җитәкчелек итә, – дип искәртте Фәрит Мөхәммәтшин. – Бу юнәлештәге эшне көчәйтеп җибәрү өчен күп тырышлык куела».

Шуннан соң республика парламенты башлыгы Закон чыгаручылар советының Кырымның һәм Севастопольның шәһәрен Россиянең хокук системасына кертү мәсьәләләре буенча комиссия утырышында катнашты. Ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү көн тәртибендәге төп мәсьәләгә әйләнде.

Фикер алышу кысасында Фәрит Мөхәммәтшин Кырым Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Владимир Константиновка Кырымның фашистлар оккупациясе корбаннары мемориалы төзелешендә Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган татарстанлылар хөрмәтенә истәлек билгесе урнаштыру тәкъдиме өчен рәхмәт белдерде.

«Республикада бу тәкъдим тулысынча хупланды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Һәйкәл булдыру эше алып барыла. Аны киләсе елның 9 Маенда ачу күздә тотыла». Ул шулай ук республика парламенты делегациясенең әлеге истәлек билгесен ачу тантанасында катнашачагын да әйтте.

ТӨЗҮЧЕЛӘРГӘ БЕРНИ КИРТӘ ТҮГЕЛ

Төзелеш

Кемгә – су, кемгә – торак. Татарстанда «Торак һәм шәһәр мохите» дип аталган илкүләм проект кысасында быел 6,5 млрд сум күләмендә акча тотылган. Әлеге илкүләм проект «Торак», «Уңайлы шәһәр мохите тудыру», «Чиста су», «Яшәргә яраксыз торак фондын киметүне тәэмин итү» федераль проектларын үз эченә ала.

Быел «Торак» федераль программасы ярдәме белән республикада 16 объект сафка басачак. Шуның 11ендә инде эшләр тәгәлләнгән. Бу хакта «Татар-информ»да узган очрашуда Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының беренче урынбасары Алексей Фролов сөйләде.

– «Шәһәр мохите» федераль программасы элек Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән тормышка ашырылды. Хәзер инде без бу максатларда федераль бюджеттан ярдәм алабыз, – ди Алексей Фролов. – Республикада «Чиста су» программасы буенча да шактый эшләр башкарыла. Төп максат – авыл җирләрендә яшәүчеләрне чиста су белән тәэмин итү. Ел саен «Чиста су» программасы өчен дәүләттән 1 млрд 300 мең сум акча бирелә.

Шушы урында су кертү буенча сораулар туды. Ник дигәндә, су капка төбенә килә, аны өйгә кертү – хуҗа эше. Су дигәч, авыллары «Чиста су» программасына кертелеп тә, аңа тилмерүчеләр искә төште. Моңа кадәр «ВТ» битләрендә сусызлык турында язмалар аз язылмады. Буа районының Иске Суыксу авылында яшәүчеләрнең дә суга тилмергәнен үзебез күргән идек. Язманы әзерләгәндә, яңадан аларның хәлләрен белешеп алдык. Баксаң, әлегә аларның бәхетле чорлары. Баксаң, кыш айларында суга кинәнәләр икән. Ә менә җәен су күрәм, димә.

– Кышка кергәч, яшиселәр килә башлый инде, – ди Иске Суыксу авылында гомер итүче Гөлфия Сафина. – «Чиста су» программасын көтә башлаганга 5 елдан артып китте. Рәхәтләнеп су да эчкән юк. Авылга су кертә башлагач, аксакаллар аның элеккеге юлын күрсәтеп тә йөрде. Әмма су кертүчеләрнең үз планнары иде. Алар әллә каян, еракпаннар су юлы артылар. Җәйләрен су килгәндә, без аны тизрәк җыеп калабыз. Әмма 2–3 көн торса, ул яшелләнә.

Авыл халкының бер шатлыгы бар: иске су башнялары да яңартылып, суны суыртү өчен махсус насослар куелган. Ничек тә су проблемасын хәл итәргә тырышалар икән.

Алексей Фролов авыл халкын сулы итәселәрен әйтсә, шәһәрнекеләргә ял итәр өчен мөмкинлекләр тудырылганы санап китте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Быел «Безнең ишегалды» программасы ярдәме белән 2212 ишегалды төзекләндерелде. Хәзер инде 2023 елдагы эшләргә әзерлек бара. Карлар эреп бетүгә, төзүчеләр ишегалларын яңартырга тотыначак, – диде ул.

Министр урынбасары торак төзелеше хакында да сөйләде. Аның сүзләренчә, республика төзүчеләргә алда бара. 2022 елга 2 млн 759 мең квадрат метр торак төзелергә тиеш булса, алар аны 10 процентка арттырып үтәгәннәр. Төзүчеләр аварияле йортларда яшәүчеләрне дә фатир белән тәэмин итәргә җыена. Әйтик, андылар өчен йортларның алтысы Сабада салынган инде. Әмма шунысы бар: әлеге йортларда яшәргә теләүчеләргә ул бушка бирелми. Иң элек яшәгән торакларының бәясен билгелиләр, калган өлешен ипотека аша түләргә туры килә. Алексей Фролов, бу мәсьәләләр һәр районның хакимиятендә хәл ителә, ди.

Әгәр кеше үз көче белән йорт салырга җыена икән, аңа дәүләттән ярдәм каралганмы? Министр урынбасарына шул сорауны да бирделәр. Ул, андыйлар «Авыл ипотекасы» программасында да катнаша алалар, диде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҮЗ БАШЫҢНАН КИЧСӘ ГЕНӘ...

Ата-аналар җыелышы

Физик мөмкинлекләре чикле булган баланы ничек тәрбияләргә? Әти-әниләр үзләре бу хәлне ничек кабул итә? Үзенчәлекле бала өчен инклюзив мохит булдыру кирәкме? Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы туры эфирда уздырган «Ата-аналар җыелышы»нда әнә шулар хакында сөйләштеләр.

«Ата-аналар җыелышы»нда Казанның сәламәтлеге чикләнгән балалар укый торган 61 нче мәктәп директоры Жанна Семякина үзенчәлекле балаларның укуын оештыру турында сөйләде. Ул әти-әниләргә үзләре тормышка ашыра алмаган хыялларын балаларга такмаска киңәш итте.

– Бала үзе сайларга тиеш. Безнең өчен иң мөһиме – аңа уңайлы тәрбияви мохит оештыру. Бигрәк тә бу психологик тайпылышлары булган балаларга кагыла. Гадәттә, проблема балада түгел, ә әти-әнидә була. Шуңа алар белән күбрәк эшләргә кирәк. Без инде 7 яшендә баланың нәрсәгә сәләтле икәнен аңлыйбыз. Безгә күп кенә әти-әни килеп, 1–2 ел сезнең мәктәпкә йөртәбез дә, аннан гади мәктәпкә күчерәбез, диләр. Тик монда һәр очракның үзенчәлекле булуын аңларга кирәк. Бу мәсьәләләрне табиб белән киңәшләшеп хәл итегез, – диде ул.

Әти-әни баласының үзенчәлекле булуын ничек кабул итә? Ул нәрсә эшләргә тиеш? Бу сорауга Республика балалар клиник хастаханәсе медицина психологы Лия Бодрова җавап бирде.

– Әлбәттә, бу – бик авыр һәм күп энергия сарыф итә торган юл. Стресслы вакыйгаларга кешенең баш мие, гадәттә, стадияләр белән җавап кайтара. Беренчесе – шок кичерү. Монда әти-әни әле ни булганын аңламый. Икенчесе – кире кагу. Бу этапта әти-әни үз баласы өчен ярдәм эзли. Өченчесе – агрессия. Аларның бөтен нәрсәгә ачулары килә башлый. Монда шуны да аңлау мөһим: үзенчәлекле баланың әти-әнисе берни белән дә аерылмый. Без барыбыз да шундый ук хисләр кичерәбез, ачуланабыз, кайгырабыз. Бу – нормаль күренеш. Бу этапта ата-ананың бурычы – әлеге хис-кичерешләрне кабул итү, – дип сөйләде Лия Бодрова. – Агрессия стадиясеннән соң депрессия башлана. Әти-әни баласының киләчәк тормышы турында уйлана башлый. Аны җәмгыятьтә кабул итмәсәләр, үчекләсәләр? Бала үзенә урын таба алмаса? Бу этапта баш миенә чишелеш табу мөһим. Кеше әкренләп моны җиңәргә мөмкин булуын аңлый башлый. Сорауларга җавап таба башлау белән, кеше дә авырлыкны кабул итә, – диде медицина психологы.

Юрист, психологик тайпылышлары булган 18 яшьтән өлкәнрәк инвалид балалар һәм инвалид балаларның ата-аналары Бөтенроссия оешмасының төбәк бүлеге координаторы Ригина Садыйкова үзе дә – үзенчәлекле бала әнисе. Аның кызында – беренче типтагы шикәр чире. Әни кеше үз тәҗрибәсе белән уртаклашты:

– Кызыма шикәр чире диагнозын 11 яшендә куйдылар. Безнең гаилә өчен бу зур фаҗига иде. Мин бу проблемадан чыгу юлын табарга тырыштым, баламның тизрәк терелүен теләдем. Аңа кирәкле вакытта ярдәм итә алмам дип бик курыктым. Ике ел узгач, психологик ярдәм сорап, Лия Бодровага мөрәҗәгать иттек. Ул безгә бик нык булышты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Төбәк белән идарә итү үзәге (ЦУР) 2022 елда мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә кагылышлы четерекле мәсьәләләрне ачыклау максатыннан сораштыру үткәргән. Күп кеше, инвалидларга җәмгыятькә җайлашуда төп киртә булып, стереотиплар, аларны авыр йөк итеп кабул итү кебек сәбәпләр тора, дип җавап биргән.
Халыкның сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәте нәрсәгә бәйле булырга мөмкин?
41% – мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр турында стереотиплар белән уйлый;
31% – андый кешеләрне җәмгыять өчен авыр йөк дип саный;
22% – аларның проблемалары һәм ихтыяҗлары кирәгеннән артык дип исәпли;
20% – инвалидлар янында үзен ничек тотарга икәнен белми;
14% – уртак кызыксынулары юк;
5% – аларның үз дуслары бар, алар арасына беркемне дә кертмиләр, дип уйлый.

Ригина Садыйкова әйтүенчә, баласына диагноз куелгач, аның бер генә кеше белән дә сөйләшәсе килмәгән. Ярдәмне бары тик әти-әниләр җәмгыятендә генә тапкан.

– Бу фаҗига белән көрәшергә миңа шундый ук хәлгә эләккән кешеләр белән аралашу ярдәм итә. Үзләре дә моның аша узган әниләр миңа ярдәм кулы сузды, һәрвакыт безнең янда булдылар, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәт ветераны **Ханзафаров** Назыйм Габдрахман улына, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының дәүләт хезмәтен үстерү бүлеге баш киңәшчесе **Черемушкин** Андрей Дмитриевичка, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе режиссеры ярдәмчесе **Калинина** Ирина Юрьевнага, Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының фәнни-аналитика бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Алексеева** Альбина Анатольевнага, Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының гомуми бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Гатина** Лилия Солтан кызына, Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының фәнни-аналитика бүлеге башлыгы урынбасары **Сафиуллина** Юлия Владимировнага, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башлыгы урынбасары **Җамалетдинов** Габдерәшид Мөдәрис улына, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе референты **Мифтахов** Рәис Габделәхәт улына, нефть сәнәгате ветераны **Леушин** Владимир Егоровичка, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Зәй дәүләт район электр станциясе» филиалы граждан оборонасы штабы башлыгы **Волков** Алексей Андреевичка, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе 35 номерлы участогының 5 номерлы цехы контроль-үлчәү приборлары һәм автоматиканы төзекләндерү буенча өлкән мастеры **Волков** Андрей Андреевичка, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең Казан шәһәрендәге территориаль идарәсе профилактика бүлеге әйдәүче белгече **Насыйбуллина** Евгения Максимовнага, «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү фельдшеры **Сидоров** Александр Владимировичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Бизнеска хезмәт күрсәтү үзәге Персонал белән эшләү үзәгенең персоналны укытуны оештыру бүлеге укытуны оештыру төркеме белгече **Синчугова** Мария Федоровнага, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Зәй дәүләт район электр станциясе» филиалы электр цехы җиһазларын төзекләндерү буенча мастеры **Фокин** Владимир Геннадьевичка, «Аммоний» акционерлык җәмгыяте карбамид җитештерү цехының чимал әзерләү һәм ярымфабрикатлар һәм продукцияне төяп озату буенча аппаратчысы **Шәйдуллин** Ренат Рамил улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

«Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гайнуллов** Рөстәм Мөнир улына, «Автодор» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Идрисов** Эдуард Зөфәр улына, «КАЗАН ПРОМСТРОЙПРОЕКТ» ИНСТИТУТЫ ачык акционерлык җәмгыятенең проект баш инженерлары бюросы проект баш инженеры **Кукуева** Татьяна Александровнага, «Камэнергостройпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте стропальщигы **Латыйпов** Хәләф Миңлебай улына, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Кама аръягы территориаль бүлеге баш белгече **Миниханов** Илдар Хәлим улына, «Камэнергостройпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кулдан электр белән эретеп ябыштыручысы **Морозов** Радик Николаевичка, «Камэнергостройпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тимер-бетон эшләнмәләр һәм конструкцияләр формовщигы **Нәбиуллин** Зөлфәт Рухулла улына, «СтройГрад» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Татаркин** Валерий Николаевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе төзелешне оештыру хезмәтенең техник күзәтчелек бүлеге әйдәүче инженеры **Фәрдетдинов** Марат Нәкыйп улына, «БАРСЭЛИТСТРОЙ» төзелеш компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хөсәенов** Илһам Габделфәрт улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Эш һәм аш

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Нурлат районы эшмәкәре Илсур Мөхәммәдьяровның үтенече Фәрит Габделганиевне кызарырга мәҗбүр итте. «25 ел буе автомобиль запас частьлары сату белән шөгыльләнәм. Салымнарны вакытында түлим, башкаларны эшле итәм. Тик мондый гаделсезлекне моңарчы күргәнем юк иде. Шәһәрне төзекләндергән вакытта минем кибеткә юлны ябып, тротуар ясап куйдылар. Хәзер машина белән якын килә торган да түгел. Шуның аркасында керемем икеләтә кимеде. Тугыз эшченең икесен кыскартырга туры килде», – дип сөйләде ул. Җирле җитәкчегә сүз биргәч, эшмәкәрнең башкарма комитетка мөрәҗәгать итмәвен әйттеләр.

«Кибетне юлга тоташтыруда кыенлык бармы-юкмы, булса, хәл итү җаен табыгыз», – дип, озакка киткән сүзгә нокта куйды Президент. Фәрит Габделганиевкә мөрәҗәгать итеп: «Көндәлек тәртиптә хәл ителәсе мәсьәләне бу дәрәҗәгә күтәреп, бөтен республика алдында оятка каласың. Башка эшең беттеме әллә? Син – шуның өчен дә Президент ярдәмчесе бит, эшләргә кирәк», – диде.

Президентка өчпочмак турында мультфильм да күрсәттеләр. Башкалада урнашкан анимация студиясе җитәкчесе Артур Шамшадинов сабыйлар өчен тәрбияви мультфильмнар төшерүләре турында сөйләде. Өчпочмак турындагысы, мәсәлән, ризык белән уйнамаска өйрәтә. Без акча сорамыйбыз, дип залда утыручыларны көләргә мәҗбүр иткән егет, республикада төрле проектларны тормышка ашырганда, бу эшкә үзе кебек яңача фикер йөртүчеләрне дә җәлеп итүләрен сорады. Бары тик шул гына!

– Хәл итә алмаслык мәсьәләләр юк, – дип, очрашуга йомгак ясады Рөстәм Миңнеханов. – Без эшмәкәрләргә тиешле шартлар тудырырга тиеш. Алар үзләрен дә, башкаларны да эшле-ашлы итә бит. Без алга таба да эшмәкәрләргә ярдәм итәчәкбез.

Кыен хәлдә калган эшмәкәр Илсур абыйның да кәефен күтәрергә тырышты ул. «Барысы да әйбәт булачак», – диде Президент кибет хуҗасына.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Белдерү

Информация о результатах аукционов на право заключения договоров о создании искусственных земельных участков

ГБУ «Республиканская имущественная казна» (организатор торгов, специализированная организация) и Министерство земельных и имущественных отношений Республики Татарстан (уполномоченный орган), сообщают о результатах 4-х (четырех) открытых аукционов на право заключения договоров о создании искусственных земельных участков на Водном объекте (Куйбышевское водохранилище. Водохозяйственный участок – 11.01.00.001 – Волжский участок Куйбышевского водохранилища от г. Казань до пгт Камское устье. Код водного объекта: 11010000121412100000010), с планируемым местоположением: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казани, Волжские поля, Кировский район, акватория Куйбышевского водохранилища, назначенных на 2 декабря 2022 года в 10.00 часов. Согласно Протоколам приема заявок на участие в аукционах от 01.12.2022 г. аукционы признаны несостоявшимися, ввиду подачи одной заявки и признания заявителя единственным участником аукционов. Договора о создании искусственных земельных участков заключены с единственным участником по начальной цене права на заключения договора.

Шәҗәрә

ВАСЫЯТЬ

Яңа Чишмә районы Зирекле авылында Газыймовлар гаиләсен туган як тарихын өйрәнүчеләр буларак кадерлиләр. Шуңа күрә Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты оештырган «Без тарихта эзлебез» фестивалендә катнашып, җиңүгә ирешүләре бер дә гаҗәп түгел аларның.

Ни кызганыч, 80 яшен тутырган гаилә башлыгы Мидхәт ага гына күптән түгел бакыйлыкка күчкән булып чыкты. Күрешергә дә, сөйләшергә дә насыйп булмады. Әмма шунысы сөенечле: авыл аның истәлекләре белән яши. Бу бүген генә түгел, буыннан-буынга шулай дәвам итәр әле, чөнки ул, авыл тарихын өйрәнеп, музей төзеп калдырган.

Соңгы хат

Мидхәт ага гаиләдә бишенче бала булып, 1942 елның 2 гыйнварында дөньяга аваз салганда, аның әтисе Гариф сугыш кырында дошманнарга каршы көрәшә. Ул 1941 елның декабрендә фронтка алына һәм 1943 елның февралендә Великие Луки шәһәре госпиталендә сугыштан алган яралардан вафат була. Ата белән ул күрешә алмыйлар. Әниләре Рәхилә биш баланы берүзе тәрбияләп үстерә. Әтисенең төпчек улына язган хаты гына кала: «Улым Мидхәт, белем алырга тырыш. Үгет-нәсыйхәтләремне васыять итеп әйтәм: туган җиреңне, туган туфрагыңны ярат. Авылыбызның тарихын, ата-бабаларыбызның нәселен өйрән, киләчәк буынга, халыкка тапшыр, туганнар белән элемтәне өзмичә, аны ныгытып, кулыңнан килгәнчә ярдәм ит...» Бу Гариф абыйның соңгы хаты була. Мидхәт абый бәйгегә әзерләнгәндә мондый сүзләр язып калдыра: «Мин гомерем буена әтиемнең васыятен истә тотып, аны үтәргә тырышып яшәдем».

Музей

Урта мәктәпне тәмамлагач, егет ерак китми, шунда ук электромонтер булып эшкә урнаша. Бер елдан соң Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга керә, башлангыч сыйныфларда рус теле һәм рәсем дәресләре укыта башлый. Совет Армиясе сафларында өч ел хезмәт итеп кайтканнан соң ул, киләчәкне уйлап, төпле адым ясый: тарих бүлегенә күчә. Авыл мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме дәресләре укытырга алына. Туып үскән «Кичуй» колхозы тарихын тикшереп өйрәнү аның диплом эше була. Мидхәт ага фикеренчә, туган як тарихын өйрәнә башлау өчен бу аңа зур этәргеч ясый. Ул, архивларда утырып, авыл, аның халкы турында материал җыя башлый. Аның җитәкчелегендә тирә-яктагы 17 авылдан Зиреклегә килеп урта белем алган укучыларның язмышларын да өйрәнәләр. Шулай итеп, мәктәптә башта «Мәктәпне тәмамлаучылар» музее барлыкка килә. Тарих укытучысы шул ук вакытта аерым бинада авыл музеен оештыру турында да хыяллана. Мәктәп музеена 10 ел тулган елны, Татарстан Дәүләт музее филиалы буларак, «Зирекле авылы халык иҗаты һәм көнкүреше» музее ачыла.

Мидхәт ага бу эшкә чын күңелдән бирелә. Музей оешкан көннән алып фондларны саклаучы булып торган тормыш иптәше Зәйтүнә апа аңа ярдәм итә. Зирекле кызы булгач, аның күңеленә дә бу эш бик якын була. Мәктәптә дә бергәләп эшлиләр: Алабуга педагогия институтын тәмамлап, физика укытучысы булып кайта кыз авылга. Балалары да актив катнаша. Музейда алар иҗат иткән матур картиналар эленеп тора. Бик шәп китапханә дә бар.

2017 елга кадәр җитәкчелек итә Мидхәт ага музейга. Аннан соң да туктамый. Фәнни хезмәткәр, киңәшче буларак эшчәнлеген дәвам иттерә. Ничә еллар буена тупланган тәҗрибәсен тапшырып калдырырга тырыша. Үзенә алмаш әзерләргә дә онытмый. Мәктәп елларыннан бирле эзләнү эшләрен Мидхәт абыйсы белән бергә алып барган Лидия Лотфуллина остазының гомерлек эшен дәвам иттерергә алына. Музейның бүгенге директоры ул. «Мәктәптә музей эшли башлагач та, Мидхәт абый мине музей түгәрәге җитәкчесе итеп куйды. Тарих дәресләрен укытты. 1998 елдан музей хезмәткәре булып эшли башладым. Остазым янәшәсендә 24 ел хезмәт куйдым», – ди Лидия Зөфәр кызы бу җәһәттән.

Күпьеллык хезмәт нәтиҗәсе буларак, авыл һәм аның халкы турында алты китабы, бәет җыентыклары һәм башка китаплары дөнья күрә Мидхәт аганың.

Бүген музейда 1356 төп һәм 71 өстәмә фонд экспонатлары саклана. Монда авыл кешеләре кулы белән дистә еллар буена ясалган әйберләр: сөлгеләр, намазлык, эскәтерләр, чигелгән мендәр тышлары һәм башка бик күп нәрсәләр бар. Аларның күбесе XIX гасыр урталарыннан XX гасыр урталарына чаклы эшләнгән. Бүгенге эшләнмәләр дә байтак. Татарстан Милли музее белгечләре бәяләгәнчә, Зирекле музееның сөлгеләр коллекциясе – республикада иң саллысы. Бу – Мидхәт абыйның зур казанышы.

Бәйгедә дә музейдагы экспонатларның бер өлешен күрсәтергә тырыша алар. Татар сөлгеләрен күргәч, җыелган халык сокланудан аһ итә.

– Бүген музеебызда 340 сөлге саклана, – ди Лидия ханым. – Алар арасында Газыймовлар һәм Лотфуллиннар эшләгәннәре шактый. Зәйтүнә апа чиккән «бирнә сөлгесе» дә биредә саклана. Гомумән, бу нәселнең барлык хатын-кызлары да кул эшләренә бик оста булган. Кияүгә чыкканда, һәрберсе ир-егетләренә сөлге чигеп бүләк иткән. Әбиләре тукыган станок та биредә саклана.

Музей ачылганнан бирле анда 30 меңнән артык кеше булган, 1,5 мең экскурсия, 370 массакүләм чара үткәрелгән. Бөтен шартлар булганлыктан, берничә тапкыр музей хезмәткәрләре семинарлары да узган. Соңгы елларда Мидхәт ага район авыллары тарихы турында материаллар да җыя башлаган була.

Тап төшерми

Кыскасы, Ватанны яклап кан койган әтисенең йөзенә дә, васыятенә дә тап төшерми ул. 1999 елда Мидхәт Газыймовка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Ул – хезмәт ветераны. «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә. Мактау грамоталары, дипломнары, Рәхмәт хатлары да бик күп. Музей төрле бәйгеләрдә берничә тапкыр җиңеп тә чыга.

Авыл халкы өчен үрнәк булып торган Газыймовлар гаиләсендә биш бала үсә: кызлары – Алсу, Чулпан, Ландыш, уллары – Булат, Алмаз. Барысы да гаиләле, балалар тәрбиялиләр. Һөнәр сайлаганда да әти-әниләре эзеннән әллә ни тайпылмыйлар. Укытучылар да, журналистлар да, тәрбиячеләр дә бар арада. Кече уллары Алмаз гына нефтьче эшен үз иткән. Алар барысы бергә үз нәселләрен тугыз буынга кадәр өйрәнеп, 497 кешене барлыйлар. 2007 елда алар бергәләп Псков өлкәсе Великие Луки районындагы Беседино авылына, Гариф ага җирләнгән туганнар каберлегенә барып кайталар. Димәк, үзе сугышка киткәндә, әле ана карынында гына калган балага шундый зур эш йөкләп, бер дә ялгышмаган ата.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Мәгълүмат санлаша

Тузан кунган, халык эзен суыткан, тормыш туктап калган урын түгел. Киресенчә дә әле. Республиканың Архив эше буенча дәүләт комитеты үз эшчәнлеге белән бу сүзләрне дәлилли. Ел буе нәрсә эшләгәннәр һәм нинди нәтиҗәләре белән уртаклаша алалар?

Комитет җитәкчесе Гөлнара Габдрахманова алдан ук кисәтеп куйды: архив – архаик (ягъни бик борынгы, иске) урын түгел. «Курыкмыйча әйтә алам: хәзерге көндә Татарстан архивлары тармакка санлы технологияләр кертү җәһәтеннән Россиядә иң яхшылары. Без башка төбәкләрдән күпкә алгарак киттек, күп кенә нәрсәләрне, бигрәк тә цифрлаштыруга бәйлеләрен, беренчеләрдән булып без уйлап табабыз, аннан исә бу тәҗрибәне башка төбәкләр куллана. Безнең фикерне ишетәләр», – диде ул.

Нәрсәдә алдынгы соң республика архивы? Әйтик, архивка кергән документларның бәһасен ясалма интеллект нигезендә тикшерергә телиләр. Гөлнара Габдрахманова сүзләренчә, әлегә проект документациясен эшлиләр. Аннан проект чын-чынлап гамәлгә ашырыла башлаячак. Ясалма интеллект тикшерүеннән соң калган иң кызыклы документларны инде чын белгечләр тикшерәчәк.

Моннан тыш читтән торып уку модулен камилләштерергә җыеналар. Аңа түләү системасын тоташтырмакчылар. Электрон имзаның куллану вакытын озайту буенча сорауларны да хәл иткәннәр.

Гараж-чормаларда көн итү юк. Комитет башлыгы әйтүенчә, Татарстан архивларының барысының да диярлек үз йорты бар. «Чорма, гараж, подвалларда эшчәнлек алып барган муниципаль архивлар калмады диярлек. Татарстан Президенты ярдәме белән, барлык архивларны да төзекләндердек», – диде Гөлнара Габдрахманова.

Архивларның ни белән шөгыльләнүләрен күрсәтә белү дә кирәк. Дәүләт архивын оештыруда алыштыргысыз булып саналганнарныкын аеруча. Шул максаттан 2018 елдан бирле коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар арасында иң яхшы архивны ачыклау буенча бәйге үткәрелеп килә. Гөлнара Габдрахманова китергән мәгълүматлар буенча, быел конкурста 51 оешма катнашкан. 12се җиңү яулаган. Җиңүче архивларны Татарстан Президенты да котлаган. 1 урынга – 1 млн, 2 урынга – 750 мең, 3 урынга 500 мең сум күләмдә акчалата бүләк каралган. Моннан тыш, быел авыл җирлекләре өчен аерым номинация дә булдырганнар. Рөстәм Миңнеханов 6 авылның һәркайсына 375әр мең сумлык сертификат биргән. Билгеле, матди бүләк архив эшен тагын да уңайлату, биналарны кирәкле җиһаз белән тәэмин итү өчен ярап куячак.

Моннан тыш Архив эше буенча дәүләт комитеты 2017 елдан бирле муниципаль архивлар өчен грант оту мөмкинлеген дә тудыра. Быел конкурста 29 районнан 32 проект катнашкан. 15 архивка уңыш елмайган – грантлы булганнар.

Архив эшчәнлеге турында сөйләгәндә, Гөлнара Габдрахманова ел да зурлап оештырыла торган шәҗәрә төзү, нәсел-нәсәпне барлауга багышланган бәйгеләрне дә телгә алды. Бәйгеләр турында да, җиңүче гаиләләр турында да «ВТ» укучылары яхшы беләдер. Алар турында газета битләрендә язмалар даими чыгып торды.

Республиканың архив фондын тулыландыру өчен, гаилә архивын тапшыру мөмкинлеге дә бар. Моның өчен даими рәвештә махсус бәйге дә оештыралар. Гөлнара Габдрахманова сүзләренә караганда, конкурста җиңүчеләр өчен 50, 30, 20 мең күләмендә акчалата бүләкләр дә каралган. 2022 елда 23 район катнашкан, 4 җиңүче ачыкланган.

Гөлнара Габдрахманованың Татарстан архивларына биргән бәясе белән федераль кунаклар да килеште. «Россия иҗат эшчәнлеге нәтиҗәләре хокуклары әйләнеше үзәге» оешмасы рәисе урынбасары Ирина Яковлева әйтүенә, Татарстанның дәүләт архивлары архив эшен цифрлаштыру өлкәсендә алдынгылар. Үткәннәр, тарих белән эш итсәләр дә, заманадан артта калмыйлар, димәк.

Сүз уңаеннан, Хөкүмәт йортында Татарстан Дәүләт архивы белән Россия иҗат эшчәнлеге нәтиҗәләре хокуклары әйләнеше үзәге арасында килешү имзаланды. Килешү нигезендә, республика архивы блокчейн-инфраструктурага (мәгълүматны цифрлау һәм саклау технологиясе) кушыла. Килешү Татарстандагы цифрлаштырылган документларның авторлык хокукларын якларга мөмкинлек бирәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Склероз

Дөньяда рәхәт һәм файдалы авырулар да булырга мөмкин икән, шуларның берсе – склероздыр. Авырган кешенең үзенә бик җиңел түгелдер инде, бәлки, әмма аның тирәсендәгеләргә… Бер анекдот бар бит әле… Туксан тугыз яшьлек бабай егерме тугыз яшьлек кәләш алып кайткан. Көлгәннәр инде тирә-юньдәгеләр, шушы хәтле яшь арасы бит, олы кешенең бик рәте дә юктыр, гүләйт итәр инде бу чибәркәй, дип гөманлаганнар. Ә теге яшь хатын иренә чат ябышып яши икән, кадерләп-тәрбияләп кенә тора, тәмле ризыклар гына пешерә, матур киемнәр генә кидерә, өрмәгән җиргә дә утыртмый. Яшьрәк ир-егетләр шаян сүз катып, төрле тәкъдимнәргә ишарәләп маташса да, һич исе китми, бар дип тә белми, үз бабае өчен өлтерәп тора. «Сәбәбе нәрсәдә соң моның?» – дип баш ватканнар инде күршетирәдәгеләр.

Ә сәбәбе гади генә булып чыккан. Склероз икән бабайда. Ул үзенең ничә яшьтә икәнлеген оныткан. Утыздамын, дип уйлаган. Шуңа моның үз-үзен тотышы да, сәламәтлеге дә, дәрт-дәрманы да утыз яшьлек ирләрнеке кебек икән. Алай гына да түгел әле: ул хатынын әле яңарак кына иркәләп-назлаганын оныта да, аз гына вакыт узуга, тагын тотына икән. Матур сүзләр, яратып-сыйпап иркәләүләр беркемгә дә беркайчан да артык түгел бит инде. Менә шулай булгач, хатыны да кадерен белеп кенә тора икән тегенең.

Гомумән, мәхәббәттә склероз, бәлки, иң кирәкле нәрсәләрнең берседер әле ул. Беренчедән, ярату хисе мәңгелек двигатель түгел бит инде, гел генә зырылдап эшләп утырмый, кайчагында сүрелеп тә китә, гөлтләп сүнгән кебек тә була, пыскуга да күчеп ала. Шуңа күрә аны һәрдаим яңартып торырга кирәк. Сөйгән кешеңне ким дигәндә көненә берәр тапкыр яңадан яуларга, аны яңадан гашыйк итәргә. Алай ук булмаса да, гаилә тормышында склерозның файдасы зур. Әйтик, менә биш минут элек кенә хәләлең белән әйткәләшеп алдың ди. Үпкә саклап, аның сүзләрендә, үз нәфрәтеңдә казынып йөри башласаң, мәңге рәхәт күрмәячәксең. Ә менә склероз… Биш минут элек кенә талаштың да оныттың һәм яңадан ярашып яши башладың. Шәп бит инде!

Минем бер иптәш малай бар иде. Ул һөнәрчелек училищесында укып, унсигез яшендә автомобиль йөртү хокукы алды. Шуннан гаиләләрендә бәйрәм шикеллерәк нәрсә оештырдылар. Ә бабалары… Ару гына кеше иде инде ул, кайда икәнен тәгаен белмим, тик урында эшләгән. Шуның дәлиле шикеллерәк булып торучы «Волга» машинасы да бар иде. Вәт, шул егетнең бабасы оныгына «Волга» бүләк итте.

– Бик акыллы бала булдың, улым, ни кушсам, шуны тыңлап-үтәп тордың. Укуда да гел алдынгы булдың, спортта да уңышларга ирешеп сөендердең, хәзер менә икенче разрядлы механизатор дигән таныклыгың, автомобиль йөртү хокукың бар. Рәхмәт шулай безне сөендереп яшәгәнең өчен. Юлларың алда да гел уңып торсын, безнең шатлык-куанычыбыз булып кал. Мин сиңа үземнең «Волга»мны бүләк итәм.

Бәйрәмгә җыелучылар гөрләтеп кул чапты. Күзләрендә очкын кабынды. Малайга уңышлар теләделәр, аның өчен сөенделәр. Мин чүт кенә көнләшеп тә куйдым. Унсигез яшеңдә машина хуҗасы булу уен нәрсә түгел иде ул чакларда. Бер мин генә түгел, егетнең әнисе дә аз гына көнләшеп куйды бугай.

– Бәхетле инде син, улым, әле хәтта әтиеңнең дә «Волга» руле тотып караганы юк, – диде. Бәлки, көнләшү дә түгелдер инде бу, ирен чеметергә чыккан җайны кулдан ычкындырмаска тырышу гына булгандыр. Тик минем хәтердә калды.

Егет бер ел чамасы йөрде теге машинада. Ул чорда әти-әни бүләгеннән күктән яуган нәрсә кебек күреп кадерсезләү гадәткә кермәгән иде әле. Карап тотты «Волга»сын, кадерләп йөртте. Нәрсәләрендер төзәтте, нәрсәләрендер алыштырды. Шулай бер елга якын йөргәч, бабасы бер-ике көнгә генә дип алып торды да кире кайтарып бирергә онытты. Кайтарды инде ул аны барыбер. Вузга кергәнен белгәч, туган-тумачалары җыелган бер табында бик матур сүзләр сөйләп, кунаклардан кул чаптырып, теге «Волга»ны икенче тапкыр бүләк иткән. Бу юлы бик йөри алмады егет ул машинада. Студент кеше бит. Профессорлар «Москвич»та йөргәндә, алар янына «Волга» белән килеп туктау әдәпсезлек булып тоела иде. Юк, моның өчен беркем дә гаепләми, тик үзеңә генә уңайсыз була торган иде. Башка төрлерәк дәвер иде инде ул, мөлкәт белән мактану урам уртасында шәп-шәрә йөргән кебек тоела торган заман иде. Шуңа егет вузда укыганда «Волга»сы гаражда торган. Ә көннәрнең берендә машинаны бабасы килеп алган. Күп йөрмәгән инде ул анда. Шуннан соң, машинаны оныгының туенда да бүләк итте. Матур сүзләр әйтеп, кул чаптырып.

Склероз әле ул икътисади яктан да файдалы. Тагын бер танышымның әтисе шундый авыру белән… «интегә» дисәң, чынлап интегүчеләрне мыскыл иткән кебек була, «ләззәтләнә» дияргә дә тел бармый… Шундый авыру белән авырый инде, кыскасы. Ә аның хатынынннан урлап «заначка» яшереп куя торган гадәте бар. Малаена күрсәтә бу кайда яшергәнен. Тик соңыннан беркайчан да сорамый. Дөньясы җитеш, теге акчага мохтаҗлыгы чыкмый. Әллә ничә еллар буе шулай дәвам итә. Бер мәлне малае кызык өчен генә теге акчаларны чутлап карарга була һәм хәйран кала: биш миллион сумнан артык акча җыелган.

Менә шундый күңел күтәргеч чирләр дә була, дип әйтүем инде. Тик барыбер авыру-сырхаулар, бәла-казалар сезне читләтеп узсын. Ә хәзер склероз турында язарга мәҗбүр иткән иң мөһим нәрсә… Иң мөһиме… Тукта, иң мөһиме нәрсә иде соң әле? Нәрсә дип әйтергә теләгән идем…

«БЕР ПОТ СӨТ САУГАН АПАГЫЗ МИН!»

Харис Якупов картинасы, «Көчле кешеләр»

Бер рәсем тарихы

Питрәч районының Шәле мәктәбе музеена кергәч, күзебез сыер савучы өч кыз сурәтләнгән бер рәсемгә төште. Бу – рәссам Харис Якупов иҗат иткән «Көчле кешеләр» картинасы. Аның геройлары – яшь кызлар: Мәрзия, Фәүзия, Сәкинә. Әлеге вакыйгадан соң 58 ел вакыт үткән. Хәзер 81 яшьлек Фәүзия апа Сәйфетдинова гына исән икән.

«Эш калдырып йөрмәгез!»

Харис Якупов, 1960–1972 нче елларда Шәледә яшәп, «Көтүче малай», «Көтүчеләр», «Мәрзия тузганаклар арасында» һәм башка картиналар иҗат иткән. Аннан соң да авылга сукмакларын суытмаган. Бу авылның табигате, тырыш кешеләре аңа иҗаты өчен җим булган. Юкка гына рәссам: «Ирешелгән уңышларымның күбесе – Шәле картиналары өчен», – димәгәндер. 1964 елда ясаган «Көчле кешеләр» картинасының исеме җисеменә туры килеп тора. Чыннан да, Фәүзия апа (фотода – сулда) бик көчле рухлы хатын булып чыкты. Күргән авырлыкларын искә төшергәндә, битләре буйлап тәгәрәгән күз яшьләре үзе бер яктылыкка әйләнә. Мөлаем апаның йөзендә нур балкый. Ә тормышы эш белән үткән дә киткән…

Фәүзия апа үзенең сурәте ясалган мизгелләрне әле дә хәтерли. Кызлар Харис Якуповка: «Эшне бүлдереп йөрмәгез әле», – дия торган булган. Бу вакытта әле алар үзләренең кайчан да булса геройга әйләнәсен күз алдына да китермәгән. Ә бит бу фото Шәле кызларын илгә түгел, хәтта дөньяга да таныта. Фәүзия апага чит илләрдән дә хатлар килгән хәтта.

– Җәйләүдә төнлә кунып, сыер савабыз шулай. Харис абый Якупов, хатыны Раушанияне ияртеп, безне төшерергә килә иде. Кызларны сайлап кына алды, – дип сөйли Фәүзия апа. – Иртән сыер савып чыгам, йокы килә. Битләрне, кулларны юам да рәссам янына ашыгам. Иннек тә сөрткән булмады. Көн буе бер урында селкенмичә басып торырга кирәк. Эш беткән арада инде бу. Өстә – бала итәкле күлмәк, ак алъяпкыч. Харис абый сине әйләндерә-әйләндерә кәгазьгә төшерә. Ардырды да, атналар буена сузылды бит. Ул вакытта кияүгә чыкмаган идем әле. Бу картина Германиягә кадәр барып җиткән. Егетләрдән, сезгә кунакка кайтам, дигән хатлар килә иде. «Мин кияүдә шул», – дип алдадым. Бер белмәгән кешегә, кайтыгыз дип, ничек языйм ди? Кияүгә дә яучы килгәч кенә чыктым, урлатмадым.

Койрыкларын сабын белән юган

7 сыйныфны тәмамлагач, фермада бозаулар карый башлый Фәүзия. Күп тә үтми, сыер савучы итеп куялар. Иртәнге дүртенче яртыда ул инде – эштә. Фермага көнгә өчәр тапкыр барырга туры килгән. Үз гомерендә эшкә бер генә тапкыр соңга калган.

Фәүзия апа әйтүенчә, колхозны миллионер итү өчен, рәис Фәйзрахман Сафин сыер савучыларга нинди генә эш кушмаган. Берсенә дә каршы килмәгән алар.

– Берәр пот сөт сауган Фәүзия апагыз мин! Бер сыердан 16–17 литр сөт саудым. Кул белән 20 сыерны дигән сүз бу. 40лап бидон юдым. Эш кенә булсын миңа. Сыерларның койрыкларын сабын белән ап-ак итеп юа идем. Түшләрен кырып, мунчала белән ышкып… Ферма мөдире Хөсәен абый: «Фәүзиядән үрнәк алыгыз!» – дия иде. Иртүк сыерларның барысын да мөгезләреннән тотып, сөеп чыга идем. 40 елга якын эшләп, бер мәртәбә дә типкәннәре булмады, – ди хезмәт ветераны.

Тормыш булгач, төрле гаделсезлекләр белән дә очрашырга туры килә аңа. Әйтик, ун ай буе беренче урында барган Фәүзиянең хезмәтен бәяләмәгәннәр. Шуннан рәискә барып: «Минем нинди гаеп бар, эшләмәсәм, алай дип тә йөрмәс идем», – дип үз сүзен әйтеп кайткан.

– Колхоз рәисләре еш алышынып торды. Эшләгән елларымның кайберләрен хезмәт кенәгәсенә язмаганнар. Хисапчы янына кергән идем, белмим, ди. Минем кебекләр хәзер 27–30 мең сум пенсия ала. Ярар, мин 22 меңгә дә риза. Лаеклы ялга чыкканда, бер мактау кәгазе дә бирмәделәр, – ди ул.

Бала табарга курыкмагыз!

Ире Салих гомер буе тракторчы булып эшләгән, хәзер мәрхүм инде. Тик Фәүзия апага бала сөю бәхете эләкмәгән. «Бала табарга курыкмагыз. Алар картлыкта ташламый. Менә миңа Аллаһы Тәгалә бала бирмәде, нишләтим», – дип үкенеп тә куйды. Үзләре гаиләдә алты кыз үскән. Хәзер өчесе генә исән. Ярый, туганнарының балалары булышып тора икән. Апасының килене – социаль хезмәткәр. Мунчасын да кертә, башка эшләрендә дә булыша.

Узган кыш бу вакытта ут эчендә идем, дип, кичергән авырлыкларын да искә төшерде Фәүзия апа. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, башта егылып, аягын сындырган, аннан ковид эләктергән. Хәзер тормышына бик шөкер итә.

– Эш булмаса, Фәүзия апагыз авыруга сабыша. Кулларым кәкре булса да, туганнарыма оекбашлар бәйлим, бәрәңге утыртырга булышам. Картлык көннәрендә кеше кулларына калырга язмасын иде инде. Бөтен теләгем шул, – ди эчкерсез Фәүзия апа.

Сәрия МИФТАХОВА

БАЛАНДАЙ АЧЫ БАЛА ХӘСРӘТЕ

Язмыш

Чистай районының Дүртөйле авылында яшәүче Әлфия Минвәлиеваның сөйләгәннәрен тыңлап утыру гына да күңелдә авыр тойгылар калдырды. Бер кешегә шулкадәр хәсрәт килсә дә килә икән, дип уйладым.

– Тумышым белән шушы авылныкы мин. Бәхетсезлегемне эзләп, диим инде, Сарсаз авылына кияүгә чыктым, – дип, гомер йомгагын сүтә башлады ул. – Хәер, аңа кадәр дә 21 яшьлек бертуган энемнең фаҗигале үлемен кичереп, сынауларда сынала башлаган идем инде. Кияүгә чыккач, ирем белән әйбәт кенә яшәдек, күпмедер вакыттан соң бәби көтүемне белдек. Йөкле вакытым бик җиңел узды, бернинди дә авырлык булмады. Бәбиләр чак җиткәч, хастаханәгә бардым. Кызганыч, иң сөенечле мизгелләрем булырга тиешле көнем табиблар бәйрәменә туры килде. Температурам 42 градуска кадәр күтәрелеп, бала таба алмыйча бик газаплансам да, янымда ярдәм итәргә табиблар булмады. Бераздан килеп җиткәннәре дә үз эшләренә салкын карады. Нәтиҗәдә көтеп алган нарасыемны коткара алмадылар, үзем дә үлем белән яшәү арасында идем. Хәлем бик авыр булды. Аякларым йөрмәс хәлгә килде. Хәл алып, аякка басканчы, ярты ел вакыт кирәк булды. Аның 2,5 аен хастаханәдә уздырдым.

Дәваланып кайткач, күпмедер вакыттан соң кабат йөккә уза Әлфия Минвәлиева. Икенче улын исән-имин күтәреп, алып та кайта. Дөньялары түгәрәкләнеп, матур гына яшәгәндә, ишекләрен кабаттан борчу-хәсрәт кага.

– Ирем эшкә барган җиреннән авариягә очрады. Мотоцикл белән капланып, тәненә ут каба. Бик көчле имгәнә, исән бер генә җире дә калмый. 11 ай Чистай хастаханәсендә ятты, яныннан бер минутка да китмәдем. Аякка басуын басты, тик бу сынауларны, авыртуларны бик авыр кичерде. Хастаханәдән чыккач, озак яши алмады, үлеп китте. Ә без улым Илшат белән икәү генә калдык, – диде Әлфия Минвәлиева.

Әлфия әйтүенчә, бердәнбер газиз уллары бик акыллы, тырыш егет булып үсеп җитә. Мәктәпне тәмамлагач, Алабугада милиция мәктәбендә белем ала. Башта – Чистайда, армиядән кайткач, Казанда эшли. Анда ул бер зур оешмага икътисади куркынычсызлык буенча җавап бирүче кеше булып эшкә урнаша.

– Улым гел юлда, гел чит илләрдә командировкада булды. Соңгы китүендә: «Әни, мин Калугага барып кайтам», – дигән иде. Тик шул китүеннән әйләнеп кайтмады. 2012 елның июле иде ул. 8е кайтырга тиеш иде, тик командировкасын озынайттылар. 11 июль көнне шалтыратты. Кайтырга билет алганлыгын, эш буенча кирәкле акчаны табуын әйтте. Шуннан соң элемтәгә чыгып булмады.

Күңелем сизенгәндәй, энемнең хатынына да: «Бер дә Илшатка охшамаган бу. Ул телефонны алмыйча тормый иде бит», – дидем әле. Шуннан соң мунчага киттем. Бервакыт энемнең кызы: «Илшат абый шалтырата», – дип, телефонны китереп бирде. Мин сөенә-сөенә алдым инде, тик таныш булмаган ир миңа улымның суга батып үлүен, әлегә кадәр гәүдәсен таба алмауларын хәбәр итте. Кемнедер коткармакчы булып суга кергән, диделәр…

Тик ана күңеле моңа һич кенә дә ышанмый. Ул вакытта улының суга батып үлмәвенә ишарәләр дә күп була. Гаделлек, дөреслек эзләп, какмаган ишеге, басмаган бусагасы калмый. Тик улының милициядә эшләүче элеккеге дусларының да, башкаларның да тел төбеннән дөреслек эзләп өзгәләнүенең бернигә китермәвен, үзенә начарлык кына эшләвенә төшенә.

– Улымны артык гадел булуы харап итте. Тормышта андый да булырга ярамый икән. Улымның исемен аклап чыга, ахырга кадәр барып җитә алмадым. Иң зур үкенечем шул. Дөреслек эзләп, әрле-бирле йөргәндә, төшемә еш керде. Азрак ачыклык керә башласа, сөенечен белдерә иде. Юлымнан кире борсалар яки эшем алга бармаса, күңеле төшкән халәттә булыр иде. Андый чакларда: «Улым, нишлим соң инде тагын?» – дип үксеп елый идем. Үлеменә китергән сәбәпләрне ачыклавымны бик теләгән иде дә югыйсә. Шушы юлларда йөргәндә, улымның җитәкчесен күреп сөйләштем. Шул чагында да: «Ул бит минем бер генә бөртегем иде. Аннан башка ничек яшим хәзер…» – дип өзгәләндем, – дип искә алды ул елый-елый.

– Бер ел буе көненә икешәр-өчәр тапкыр зират юлын таптадым. Мондый хәлләр киноларда гына буладыр дип уйлыйм идем. Юк икән шул, өндә дә булырга мөмкин икән. «Улым, ач күзеңне, бу мин», «Улым, мин сине шундый сагындым», «Дөреслек таба алмадым, рәнҗемә», – дип такмаклап елап тиләрә башлаган идем иде. Кабер ташы, сыйпый-сыйпый, шомарып бетте, ахры.

Сынаулары моның белән генә туктамый әле бичара хатынның. Улының китүенә 4 ай булганда, әнисе бакыйлыкка күчә. Үзе аягын сындырып, гипс салдыра, җитмәсә, анысы уңышсыз булып чыга.

Әле ярый янында терәк булырдай, хәсрәтен күтәрешергә иңен куярдай туганнары бар Әлфия апаның. Сарсаз авылында фатиры булса да, әлеге вакытта ул энесе гаиләсендә яши.

– Алар мине үз гаиләләренә сыендырды. Монда мин үз йортымда кебек яшим. Аллага шөкер, әле ярый туганнарымнан уңдым. Бик нык ярдәм итәләр. Улым үлгәннән соң үземә берни дә сатып алганым юк. Апа белән улы, күңелемне күреп, гел бүләк итеп торалар. Улым үлгәннән соң җиде ел үз эчемә бикләнеп яшәдем, беркая да чыкмадым диярлек. Әле менә соңгы елларда гына кешеләр белән аралаша, авылдагы мәдәни чараларга чыга башладым. Җәен кызлар белән диңгезгә барып кайтабыз.

Әлфия апа бүген дә улын югалту хәсрәтеннән айный алмый кебек тоелды миңа. Аның өчен вакыт гүя ун ел элек туктап калган. Ана өчен бердәндер газиз кешесен югалту – мәңгелек һәм төзәлмәслек яра.

– Мин күрмәгән хәсрәт калмады инде, – ди Әлфия Минвәлиева. – Беренче баламны табиблар гаебе белән югалттым. Иремне, энемне бик яшьли җир куенына салдым. Улымнан соң 4 айдан әни китте… Ләкин бала хәсрәтеннән дә яманы юк икән. Әнинең бакыйлыкка күчкәнен аңларлык та дәрәҗәдә түгел идем, чөнки улымны югалту ачысыннан күзем томаланган иде. Әни юклыгын акылым белән кабул итү бераз вакыттан соң гына килде… Улымны җирләгәннән соң, өч фотосын бик зур итеп ясаттым. Бик сагынганда, күңелемә урын таба алмаганда, шуларны кочаклап елыйм хәзер. Төшләремә дә керми инде. Туганнарыбыз аша гына «хәбәрләр җиткерә». Әле менә күптән түгел генә бер туганымның төшенә кергән. «Әнигә әйтегез, еламасын. Минем монда яхшы», – дип әйткән. Шушы сүзләреннән юаныч табып яшәсәм генә инде хәзер.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 381

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+